МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.03.2016 г.Казань № 54-ОД

Татарстан Республикасы сәнәгать
һәм сәүдә министрлыгының
дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең
эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен саклау
һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү
Комиссиясе турында

2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе турында» 821 номерлы Указы, Татарстан Республикасының 2003елның 16 гыйнварындагы «Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында» 3-ЗРТ номерлы законы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссияләре турында» УП-569 номерлы Указы нигезендә, б о е р ы к б и р ә м :

1. Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе турындагы Нигезләмәне (кушымтада бирелә) расларга.
2. Җыелма бүлегенә (Гыйҗәтуллова Н.Н.) әлеге боерыкны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Хөкүмәте Рәсми порталының Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырырга.
3. Структур бүлекчәләр җитәкчеләренә әлеге боерыкны хезмәткәрләр игътибарына җиткерергә.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министр урынбасары А.Ш. Хөсәеновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр урынбасары – министр А.Ә. Кәримов

Татарстан Республикасы
сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының
2016 елның 23 мартындагы
54-ОД номерлы боерыгы
белән расланган

Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының
дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту
таләпләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү
Комиссиясе турында Нигезләмә

1. Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе турында Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) 2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссияләре турында» 821 номерлы Указы, 2003елның 16 гынварындагы «Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында» 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы, 2006 елның 4 маендагы «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 34-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссияләре турында» УП-569 номерлы Указы нигезендә эшләнгән.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычы булып ярдәм итү тора:

а) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, Министрлык) чикләүләр һәм тыюлар, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки көйләү турындагы таләпләрне үтәүләрен тәэмин итүгә, шулай ук алардан бурычларын үтәүне тәэмин итүгә, «Коррупциягә каршы тору турында» федераль законында, башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларын үтәүләренә (алга таба – эштә үз-үзләрен тоту таләпләренә һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү таләпләренә);

б) Министрлыкта коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруга.

4. Комиссия Татарстан Республикасының Министрлыкта дәүләт гражданлык хезмәткәрләре вазыйфаларында (алга таба – дәүләт хезмәт вазыйфалары) булучы

(дәүләт хезмәт вазыйфаларына билгеләнүләре һәм азат ителүләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәткәрләреннән тыш) дәүләт хезмәткәрләренә мөнәсәбәттә аларның эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен саклау һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү таләпләрен үтәүләренә бәйле мәсьәләләрне карый.

5. Министрлыкның дәүләт хезмәте вазыйфаларына билгеләнүләре һәм азат ителүләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәткәрләренә мөнәсәбәттә аларның эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен саклау һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү таләпләрен үтәүләренә бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында булдырылган эш урынында тәртип һәм мәнфәгатьләр конфликтын көйләү Комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла

6. Комиссия Министрлык боерыгы белән оештырыла. Күрсәтелгән боерык белән Комиссия составы һәм аның эш тәртибе раслана.

Комиссия составына Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары арасыннан министр тарафыннан билгеләнә торган Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, секретарь һәм Комиссия әгъзалары керә. Комиссия әгъзалары барысы да карарлар кабул иткәндә тигез тавыш хокукына ия. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссия составына керәләр:

а) министр урынбасары (Комиссия рәисе), коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар бүлеге вазыйфаи заты (Комиссия секретаре), юридик һәм кадрлар бүлеге дәүләт хезмәткәрләре, министр тарафыннан билгеләнә торган Министрлыкның башка бүлекчәләренең дәүләт хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Идарә вәкиле  һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчә вәкиле;

в) эшчәнлекләре дәүләт хезмәте белән бәйле булган фәнни оешмалар, профессиональ белем бирү оешмалары, югары белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре);

8. Министр Комиссия составына кертү турында карар кабул итәргә мөмкин:

а) 2005 елның 14 октябрендәге «Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы турында» 103-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 22.1 статьясы нигезендә Министрлык каршында барлыкка китерелгән Иҗтимагый совет вәкилен;

б) дәүләт органында барлыкка китерелгән ветераннар иҗтимагый оешмасы вәкилен.

9. Әлеге Нигезләмәнең 7 һәм 8 пункларының "б" һәм "в" подпунктларында күрсәтелгән затлар Комиссия составына билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Идарәсе яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт

хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе белән, фәнни оешмалар белән, профессиональ белем бирү оешмалары, югары белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары белән, Министрлык каршында барлыкка китерелгән иҗтимагый совет белән, Министрлыкта барлыкка китерелгән ветераннар иҗтимагый оешмасы белән министр таләбе нигезендә килешү буенча кертелә. Килешү таләпне алган көннән 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

10. Комиссиянең Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларында булмаган әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми санының дүрттән береннән дә ким булырга тиеш түгел.

11. Комиссия составы Комиссия тарафынннвн кабул ителә торган карарларга йогынты ясарга булган мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу мөмкинлеген булдырмаслык итеп формалаштыра.

12. Комиссия утырышларында киңәш бирү хокукында катнашалар:

а) Комиссия тарафыннан аңа мөнәсәбәттә эштә үз-үзләрен тоту таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү буенча таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә торган, Министрлыкта Комиссия тарафыннан аңа мөнәсәбәттә бу мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре вазыйфасы кебек үк дәүләт хезмәте вазыйфаларында булучы ике дәүләт хезмәткәре;

б) Министрлыкта дәүләт хезмәткәре вазыйфасында булучы башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм Комиссия тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә алучы белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының урындагы затлары; кызыксыну белдергән оешмалар вәкилләре; Комиссия тарафыннан аңа мөнәсәбәттә эштә үз-үзен тоту таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү буенча таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәре вәкиле, Комиссия рәисенең Комиссия тарафыннан бу мәсьәлә аңа мөнәсәбәттә карала торган дәүләт хезмәткәре, яки Комиссиянең теләсә-кайсы әгъзасының үтенече нигезендә һәр аерым очрак буенча Комиссия утырышы булырга өч көн кала кабул ителә торган карары буенча.

13. Катнашучылар Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан өчтән икесеннән кимрәк булмаган санда булган очракта Комиссия утырышы тулы хокуклы санала.

Утырышны бары тик Комиссиянең Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларында булучы әгъзалары катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

14. Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда Комиссия әгъзасының турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы туган очракта һәм бу хәл мәсьәләне караууда мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булганда ул бу хакта утырыш башланганчы белдерергә тиеш.мондый очракта Комиссиянең әлеге әгъзасы бу мәсьәләне карауда катнашмый.

15. Комиссия утырышларын уздыруга нигез булып тора:

а) министрның дәүләт хезмәткәре тарафыннан китерелгән мәгълүматларның дөреслеккә туры килүенә һәм тулылыгына, һәм дәүләт хезмәткәре тарафыннан эштә үз-үзләрен тоту таләпләренең үтәлүенә Россия Федерациясе һәм Татарстан

Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләрне раслаучы тикшерү материалларын китерүе:

дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларына дәгъва итүче гражданнарның керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирүләре турындагы, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән расланган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы Нигезләмәдә каралган дөреслеккә туры килми торган яки тулы булмаган белешмәләр бирелүне;

дәүләт хезмәткәренең эш урынында үз-үзен тоту таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү турындагы таләпләрне үтәмәвен;

б) Коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше буенча җаваплы вазыйфаи затка дәүләт органының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә кергән:

Министерлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык вазыйфаларының Министрлыкта вазыйфалар башкарганда үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Министрлык боерыгы белән расланган белешмә бирергә тиешле дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфалары Исемлегенә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасында булучы гражданинның дәүләт хезмәтеннән киткән көннән ике ел узганчы коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада хезмәт килешүе шартларында вазыйфалар башкару яки, әгәр дә бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешүе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирү турындагы мөрәҗәгате;

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр аркасында үзенең, иренең (хатының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә бирә алмавы турындагы гаризасы;

чит дәүләт билэмәсендә счетлары (кертемнәре) булган, чит дәүләт банкында акчалары һәм кыйммәтле әйберләре сакланган һәм (яки) чит ил финанс инструментларына ия дәүләт хезмәткәренең әлеге чит дәүләт законнары нигезендә вәкаләтле органнар тарафыннан билгеләнгән тыю, салынган арестына бәйле рәвештә, яки аннан, аның иреннән (хатыныннан) һәм балигъ булмаган балаларыннан тормаучы сәбәпләр аркасында 2013 елның 7 маендагы “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, аларда акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәи (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкин булмавы турындагы гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең хезмәт вазыйфаларын башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы туу турында белдерүе;

в) министрның яки Комиссиянең теләсә-кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәренең эштә үз-үзен тоту таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү таләпләрен тәэмин итү яки Министрлыкта коррупцияне кисәтүне гамәлгә ашыру буенча чараларны тәкъдим итүе;

г) министр тарафыннан дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелгән “Дәүләт хезмәтләре вазыйфаларында булучы затларның чыгымнары һәм башка затларның аларның керемнәренә тәңгәллеген тикшерү турында”гы Федераль законның 3 статьясының 1 өлешендә каралган белешмәләрнең дөреслеккә туры килмәүләре һәм тулы булмауларын раслаучы тикшерү материаллары тәкъдим ителү;

д) Министрлыкка коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмадан, Министрлыкта дәүләт хезмәткәре вазыйфасында булучы гражданин белән, Комиссия тарафыннан алдарак әлеге гражданинга әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керүгә ризалык бирелмәү яки андый гражданинга мөнәсәбәттә коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфалар башкару яки аның тарафыннан коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешүе шартларында эшләр башкаруга рөхсәт бирү мәсьәләсе каралмау шартларында, әгәр дә бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре Министрлыкта вазыйфалар башкарган чакта вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада эшләр башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый килешүе төзү турында 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законның 12 статьясының 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 64.1 статьясы нигезендә кергән белдерү кәгазе

16. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы мәгълүматларны, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисөиплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

16.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» подпункты икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать Министрлыкта дәүләт хезмәткәре вазыйфасында булучы гражданин тарафыннан коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше буенча җаваплы вазыйфаи затка бирелә. Мөрәҗәгатьтә гражданинның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган вакыты, яшәү урынының адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителгәннән соңгы ике ел эчендә башкарган вазыйфалары, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешманың исеме, урнашкан урыны, аның эшчәнлек төре, гражданин тарафыннан дәүләт хезмәте вазыйфасында булган чакта башкарган вазыйфаи (хезмәт) бурычлары, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмага мөнәсәбәттә дәүләт идарәсе буенча функцияләр, килешү төре (хезмәт яки гражданлык-хокукый), аның фаразланган гамәлдә булу вакыты, килешү нигезендә башкарыла торган эшләрне (хезмәтләрне) гамәлгә ашырган (күрсәткән) өчен түләү суммасы күрсәтелә. Мөрәҗәгатьне карау Министрлыкның коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше буенча җаваплы булган кадрлар хезмәте вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның нәтиҗәләре буенча, 2008 елның

25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында”гы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча мотивлаштырылган бәяләмә әзерләнә.

16.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» подпункты икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән китәргә планлаштыручы дәүләт хезмәткәре тарафыннан бирелергә мөмкин һәм әлеге Нигезләмә нигезендә Комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

16.3. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «д» подпунктында күрсәтелгән белдерү кәгазе Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасында булучы гражданин тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” Федераль законның 12 статьясы таләпләренең үтәлүе турында мотивлаштырылган бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра торган, коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан карала.

16.4. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» подпункты бишенче абзацында күрсәтелгән белдерү кәгазе белдерү кәгазен карау нәтиҗәләре буенча мотивлаштырылган бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра торган, коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан карала.

16.5. Әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «б» подпункты икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яки әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» подпунктының бишенче абзацында һәм «д» подпунктында күрсәтелгән белдерү кәгазен карау буенча мотивлаштырылган бәяләмә әзерләгәндә коррупция һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен вазыйфаи зат мөрәҗәгать яки белдерү кәгазен бирүче дәүләт гражданлык хезмәткәре белән сөйләшү уздырырга һәм аннан язмача аңлатма алырга хокуклы. Мәгълүмат алу максатыннан Министрлык тарафыннан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксыну белдергән оешмаларга таләпләр юлланырга мөмкин. Мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе кергәннән соңгы җиде эш көне дәвамында Комиссия рәисенә тәкъдим ителә. Таләпләр юлланган очракта мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки белдерү кәгазе кергәннән соңгы 45 көн эчендә тәкъдим ителәләр. Комиссия рәисе тарафыннан бу вакыт озайтыла ала, әмма 30 көннән артмаска тиеш.

17. Комиссия утырышын уздыру өчен нигез булырлык Министрлыкның норматив хокукый актында күрсәтелгән тәртиптә мәгълүмат алынганда Комиссия рәисе:

а) 10 көн эчендә Комиссия утырышы көнен билгели. Комиссия утырышы узачак көн, әлеге Нигезләмәнең 17.1 һәм 17.2 пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат кергәннән соң 20 көннән дә соңга калып билгеләнергә тиеш түгел;

б) аңа мөнәсәбәттә囗 эштә үз-үзен тоту таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү буенча таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт гражданлык хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка затларны коррупция һәм башка төр хокук

бозуларны профилактикалау эше өчен вазыйфаи затына кергән мәгълүмат, шулай ук әлегге мәгълүматны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) Комиссия утырышына әлеге Нигезләмәнең 12 пунктының «б» подпунктында күрсәтелгән затларны чакыру турында үтенечне карый, үтенечләрне канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау (караудан баш тарту) турында карарлар кабул итә.

17.1. Комиссиянең әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» подпункты өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр, мөлкәтләр һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә бирү өчен билгеләнгән вакыт чыккан көннән соң бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

17.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «д» подпунктында күрсәтелгән белдерү кәгазе, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.

18. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, аңа мөнәсәбәттә эштә үз-үзен тоту таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү буенча таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт гражданлык хезмәткәре, яки Министрлыкта дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасында булучы гражданин катнашында уздырыла. Дәүләт гражданлык хезмәткәре яки гражданин Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының "б" подпункты нигезендә бирелә торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерү кәгазендә күрсәтә .

18.1. Комиссия утырышы түбәндәге очракларда дәүләт гражданлык хезмәткәре яки гражданин катнашыннан башка да уздырыла ала:

а) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының "б" подпунктында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерү кәгазендә дәүләт гражданлык хезмәткәренең яки гражданинның Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтмә булмаса;

б) әгәр дә Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте булган һәм утырыш булачак урын һәм вакыт турында тиешле тәртиптә кисәтелгән дәүләт гражданлык хезмәткәре яки гражданин Комиссия утырышына килмәгәндә.

19. Комиссия утырышында Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасында булучы дәүләт хезмәткәре яки гражданинның (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка карауга чыгарылган мәсьәләләр буенча булган материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

20. Комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашкан затлар Комиссия эше барышында билгеле булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгелләр.

21. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «а» подпункты икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларына дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турындагы, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык

хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указы белән расланган Нигезләмә нигезендә бирелгән мәгълүматлар дөреслеккә туры килә һәм тулы дип билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан әлеге пунктның беренче абзацында әйтелгән Нигезләмә нигезендә китерелгән мәгълүматлар дөреслеккә туры килми һәм (яки) тулы түгел дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата анык җаваплылык чарасы кулланырга тәкъдим итә.

22. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «а» подпунктының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре эштә үз-үзен тоту таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү буенча таләпләрне үтәгән дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре эштә үз-үзен тоту таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү буенча таләпләрне үтәмәгән дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә эштә үз-үзен тоту таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү буенча таләпләрне бозарга ярамаганлыгын аңлатырга яки дәүләт хезмәткәренә карата анык җаваплылык чарасы кулланырга тәкъдим итә.

23. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» подпунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданинга, әгәр дә бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада эшләүгә яисә коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешүе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирергә;

б) гражданинга, әгәр дә бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада эшләүгә яисә коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешүе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирмәскә һәм ризалык бирелмәүнең сәбәбен аңлатырга.

24. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» подпунктының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үзенең, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмә бирелмәүнең сәбәбен объектив һәм нигезле дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үзенең, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмә бирелмәүнең сәбәбен нигезсез дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә тиешле белешмәләрне бирх буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үзенең, иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмә бирелмәүнең сәбәбен нигезсез һәм мондый белешмәләр бирүдән качу ысулы булып тора дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата анык җаваплылык чарасы кулланырга тәкъдим итә.

24.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «г» подпунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан “Дәүләт хезмәткәре вазыйфаларында булучы затларның чыгымнары, һәм башка затларның аларның керемнәренә тәңгәллеген тикшерү турында”гы Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше нигезендә бирелгән мәгълүматларны дөрес һәм (яки) тулы дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан “Дәүләт хезмәткәре вазыйфаларында булучы затларның чыгымнары, һәм башка затларның аларның керемнәренә тәңгәллеген тикшерү турында”гы Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше нигезендә бирелгән мәгълүматларны дөрес түгел һәм (яки) тулы түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылыкның анык чарасын кулланырга һәм (яки) чыгымнарны тикшерү эшләре нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки) аларның вәкаләтләре нигезендә башка дәүләт органнарына юлларга тәкъдим итә.

24.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» подпунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, аларда акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачау итә торган сәбәпләрне объектив һәм нигезле дип танырга;

б) “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, аларда акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачау итә торган сәбәпләрне объектив түгел һәм нигезсез дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата анык җаваплылык чарасы кулланырга тәкъдим итә.

24.3. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» подпунктының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз вазыйфаларын башкарган чакта мәнфәгатьләр конфликты юк дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәре тарафыннан үз вазыйфаларын башкарган чакта шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин дип танырга.

Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) министрга мәнфәгатьләр конфликтын көйләү яки аның килеп чыгуын булдырмый калу буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәре мәнфәгатьләр конфликтын көйләү буенча таләпләрне үтәмәгән дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылыкның анык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

25. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының "а-д" подпунктларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча һәм моңа нигезләр булганда Комиссия әлеге Нигезләмәнең 21 - 24, 24.1-24.3, 25.1 пунктларында каралганнардан башка төрле карар да кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләмәләре һәм сәбәпләре Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

25.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының "д" подпунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия Министрлыкта дәүләт хезмәткәре вазыйфасын башкаручы гражданинга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) әгәр дә бу оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада эшләүгә яки коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешүе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирергә;

б) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада хезмәт килешүе шартларында вазыйфа биләве һәм (яки) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада эшләр башкаруы (хезмәт күрсәтүе) 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында”гы 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен боза дип билгеләргә. Мондый очракта Комиссия министрга бу хәлләр турында прокуратура органнарын һәм белдерү җибәргән оешманы мәгълүматлаштырырга тәкъдим итә.

26. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «в» подпунктында каралган мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия карар кабул итә.

27. Комиссия карарларын гамәлгә ашыру өчен Министрлыкның тиешле тәртиптә министр каравына тәкъдим ителә торган норматив хокукый актлары проектлары, министрның карар һәм боерыклары әзерләнергә мөмкин.

28. Комиссиянең әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлары Комиссиянең утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы белән яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр дә Комиссия башка төрле карар кабул итмәсә) кабул ителә.

29. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Комиссиянең утырышта катнашкан әгъзалары имза куялар. Комиссия карары, әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» подпункты икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәсе буенча кабул ителгән карардан тыш, министр өчен тәкъдим характерында була. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» подпункты икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәсе буенча кабул ителгән карар мәҗбүрият характерында.

30. Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы көне, Комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре;

б) Комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең аңа мөнәсәбәттә эштә үз-үзен тоту таләпләрен үтәү һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазыйфасы күрсәтелгән формулировкасы;

в) дәүләт хезмәткәренә белдерелгән дәгъва, аңа нигез булып торучы материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның белдерелгән дәгъваларның асылы буенча аңлатмалары эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаучыларның фамилияләре, исемнәре, әтиләренең исемнәре, аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) Комиссия утырышын уздыруга нигез булып торучы мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның Министрлыкка керү көне;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) аны кабул итү турындагы карар һәм нигезләмә.

31. Комиссия карары белән риза булмаган Комиссия әгъзасы үз фикерен язма рәвештә белдерергә хокуклы, бу фикер Комиссия утырышы беркетмәсенә өстәлә һәм аның белән дәүләт хезмәткәре таныштырылырга тиеш.

32. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе утырыш узганнан соңгы җиде көн дәвамында министрга, тулысынча яки аннан өземтәләр рәвешендә дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары белән башка кызыксынган затларга юллана.

33. Министр Комиссия утырышы беркетмәсен карарга тиеш һәм дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чарасын куллану турында карар кабул иткәндә, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның башка мәсьәләләре буенча анда булган тәкъдимнәрне үз вәкаләтләре чикләрендә исәпкә алырга хокуклы. Комиссия тәкъдимнәрен карау хакында һәм кабул ителгән карар турында министр Комисиягә Комиссия утырышы беркетмәсе үзенә кергәннән соңгы бер ай эчендә язма формада белдерә. Министр карары Комиссиянең якындагы утырышында укыла һәм белеп тору өчен фикер алышулардан тыш кына кабул ителә.

34. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәре гамәлләрендә (чара күрмәвендә) дисциплинар гамәлләр билгеләре табылган очракта бу хактагы мәгълүмат, дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән каралган җаваплылыкка тарту чараларын куллану турындагы мәсьәләне хәл итәр өчен, министрга җиткерелә.

35. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәре гамәлләрендә (чара күрмәвендә) административ хокук бозу яки җинаять составы факты табылган очракта Комиссия әлеге гамәлләр (чара күрмәү) башкарылу турындагы мәгълүматны һәм бу фактны раслаучы документларны өч көн эчендә, кирәк булган очракта-кичекмәстән хокук саклау органнарына тапшырырга тиеш.

36. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аннан өземтә аңа мөнәсәбәттә эштә үз-үзен тоту таләпләрен үтәү һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын көйләү турындагы таләпләр турындагы мәсьәлә каралган дәүләт хезмәткәренең шәхси делосына беркетелә.

36.1. Комиссия карарыннан Комиссия секретаре имзасы һәм Министрлык печате белән расланган өземтә әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының “б” подпункты икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә аңа мөнәсәбәттә каралган, Министрлыкта дәүләт хезмәткәре вазыйфасында булган гражданинга имза куйдырып тапшырыла яки Комиссия утырышы узганнан соңгы бер эш көненнән дә соңга калмыйча, ул мөрәҗәгатьтә күрсәткән адрес буенча заказлы хат белән җибәрелә.

37. Комиссия эшчәнлегенең оештыру-техник һәм документация ягыннан тәэмин ителеше, шулай ук Комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырыш узачак көн, вакыт, урын турында мәгълүмат бирү, Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышында фикер алышуга тәкъдим ителгән материаллар белщн таныштыру коррупция һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вәкаләтле заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.